**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Пычак авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь, 2020 ел** **№3**

**«Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 26 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Арпаяз авылы, Яр буе урамы, 50 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм катнашучылар, I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар, студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Арпаяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Арпаяз авылында Яр буе урамы, 50 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Арпаяз авылының Яр буе урамында, вак таш җәеп, юллардагы чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт) (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Арпаяз авылы зираты өчен материал сатып алу;
- Арпаяз авылы зираты коймаларын төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Арпаяз авылында янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- Арпаяз авылына су тараткыч башнялар өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Арпаяз авылы суүткәргеч челтәрен капиталь төзекләндерү өчен проект-смета документларын әзерләү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- проект-смета документларына экспертиза үткәрү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Арпаяз авылының суүткәргеч челтәрен төзекләндерү, проект-смета документларын әзерләү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Арпаяз авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Пычак авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Пычак авыл җирлеге
башлыгы: Г.Ш. Нәфыйков